**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 17 октябрь № 750

г. Казань

Түбән Кама муниципаль районында жир кишәрлеген бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционерлык җәмгыятенең Түбән Кама муниципаль районында урнашкан, «Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционерлык җәмгыяте милкендә булган 4,302 гектар мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген 16:30:091501:78 кадастр саннары белән кадастр паспортында күрсәтелгән чикләрдә ял (рекреация) объекты урнаштыру максатларында махсус саклана торган территорияләр һәм объектлар категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә күчемсез мөлкәт дәүләт кадастры документларына һәм Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков